*Тема.*

# Фразеологик берәмлекләр.

**Дәрес тибы:** белемнәрне ныгыту һәм камилләштерү.

**Дәреснең төре:** гамәли дәрес.

**Җиһазлау:** татар теленең аңлатмалы сүзлеге, фразеологик сүзлек, компьютер, дәреслек

# Нәрсә ул фразеологик әйтелмә?

Үзара тыгыз бәйләнешле берничә сүздән төзелеп, бербөтен мәгънә аңлата торган күчерелмә мәгънәле төзелмә **фразеологик әйтелмә** дип атала.


1. Тыгыз бәйләнештә булу

2. Берничә сүздән тору

3. Бербөтен мәгънәдә булу

4. Телдә әзер килеш куллану

**Фразеологик әйтелмәләр – телнең матурлыгын, үткенлеген күрсәтүче берәмлекләр, телнең җәүһәрләре.**



Төшке аш
Мәктәптә
Йокы
Ял итү
Ирекле вакыт
Дәрес хәзерләү
Йокыдан тору

**Сәламәт булыйм дисәң,**

**Бар эшкә өлгерим дисәң,**

**Вакытны әрәм итмә,**

**Көн тәртибен син үтә.**

**Режим сүзе нәрсәне аңлата?**

**Режим – эштә, хезмәттә, мәктәптә, көндәлек тормышта һ.б.ш. төгәл билгеләнгән тәртип.**

(Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән).



Сул аяктан торды

Кара таңнан торды

Таң әтәчләре белән уяна

Иртән күзен тырнап ача



Чәпе-чәпе китерде

Аннан-моннан пычтырдады





**Хәрәкәттә бәрәкәт**

**Сәламәт тәндә - сәламәт акыл**

**Саулык – зур байлык**

**Аяктан егылу**

**Аякка басу**

**Тән җиңеләю**





**Ашаганда бүредәй, эшләгәндә шүредәй**

**Аш талымлау**

**Аштан өстен булу**

**Ашаганым аш түгел**



Очып барды

Канатланып барды

Канаты каерылгандай



Тел очында гына тора

Судан коры чыга

Сүз эзләп кесәгә керми

Биш бармак кебек белә



**Башы күккә тигән**

**Борынын күтәргән**

**Борыны салынган**




ЯҢА КИТАПЛАР

**Кул кушырып утыру**

**Трай тибү**

**Бармакка бармак та сукмау**





**“Эһ” дигәнче эшли**

**Башыннан ахырына кадәр**

**Кул селтәү**



**Кул арасына керү**

**Әнинең уң кулы**

**Кулдан килгәнчә**



**Әвем базарына киту**

**Изрәп киту**

***Өйгә эш.*** **Фразеологик берәмлекләр кулланып, «Минем бер көнем» дигән темага хикәя язып килергә.**